**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4716**
**17.09.2018**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегендә 2019/2020
елларның җылыту сезоны
башлану турында

Тышкы һава температурасының түбәнәюе сәбәпле, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йорт бүлмәләре һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында» 2011 елның 6 маендагы 354 нче карары, Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь комплексы буенча дәүләт комитетының «Торак фондын техник эксплуатацияләү Кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә 2019/2020 елларның җылыту сезоны башлануны билгеләргә:

1) шәһәрнең социаль билгеләнештәге объектлары (гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләре, яшьләр оешмалары) өчен – 2019 елның 18 сентябреннән;

2) шәһәрнең торак фонды өчен – 2019 елның 25 сентябреннән.

2. Җылылык челтәрләре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның җитәкчеләренә кушылган кулланучыларга аларның заявкалары нигезендә җылылык белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин